**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **13.11.2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Сарлы авыл җирлеге составына керүче
Сөендек авылында 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сөендек авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Сарлы авыл җирлеге Сөендек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә, 2 Төркем инвалидларыннан 150 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлдерергә:

- Сөендек авылында Яшел урам, Күл урамы, Кооператив урамнарындагы юлларны кырган асфальт белән ремонтлау.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарлы авыл җирлеге Башлыгы М.Р.Шәрипов